# *Ибраһимов Илдар Гомәр улы*

*Мин, Ибраһимов Илдар Гомәр улы, 1939 елның 17 октябрендә Ювас авылында тудым. Сугышка әтием һәм 3 абыем китте. Берсенә дә кире кайтырга насыйп булмады. 7 сыйныф укыдым. Хезмәт стажым 48 ел. Ат җиктем, шофёр булып та эшләдем, соңыннан 32 ел заправкада эшләдем.*

*Сугыш вакытлары бик авыр иде. Әнигә ничек булдырабыз, шулай булышырга тырыштык. Кияргә кием, ашарга ризык та булмады. Ачлыктан күкәрин, кычыткан, бәрәңге сабагы гына коткарып калды.*

*Хәзерге буын сугышлар күрмәсен, тыныч тормышта яшәсеннәр иде, тырышсыннар, әти-әниләренә булышсыннар, ялкау булмасыннар.*

